# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Конституциясенең 140 статьясына өстәмә кертү турында**

**1 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясенең 140 статьясына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9–10; 1994, № 11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 2–3; № 12; 1996, № 11; 1999, № 6, № 8 (I өлеш); 2000, № 6, № 12 (10) (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле өченче өлешне өстәргә:

«Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, аның даими комиссияләренең, Татарстан Республикасы халык депутатларының биштән бер өлешенең, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Парламент контроле комитетының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм Татарстан Республикасы Югары судының соравы буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә аңлатма бирә».

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 28 июне
№ 946